ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 февраля 2026г. № 1868

«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле өстәлгән бәягә салым күләме үзгәрү сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2024 елның 5 декабрендәге 8133 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылган вакыттан үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 25 февралендәге
1868 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 632,51 |
| 2. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, җиңел автомобильдә пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 12,65 |
| 3. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 1448,02 |
| 4. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, микроавтобуста (17 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 28,96 |
| 5. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 сәгать өчен | 1994,68 |
| 6. | Ягулык-майлау материалларын исәпкә алмыйча, автобуста (43 урыннан ким булмаган) пассажирлар йөртү буенча транспорт хезмәтләре, 1 км өчен | 39,89 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева